ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**22.02.2019**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 462**

2019 елда Зеленодольск муниципаль районында дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында

Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 44 статьясындагы 8 пунктына, 48 статьясындагы 8 пунктына нигезләнеп, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**Карар бирә:**

1. Кушымта нигезендә 2019 елга Зеленодольск муниципаль районында җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырырга вәкаләтле җирле үзидарә органнарын, бюджет учреждениеләрен һәм вазыйфаи затларны билгеләргә.

2. Җирле үзидарә органнарына, бюджет учреждениеләренә һәм әлеге карарның 1 пунктында Зеленодольск муниципаль районында дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән махсус вәкаләтле вазыйфаи затларга:

2.1. дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән бюджет акчаларын тиешле исәпкә алуны тәэмин итәргә;

2.2. максатчан билгеләнеше буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелгән матди бюджет акчаларыннан файдалануны тәэмин итәргә.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче Д.А. Сапожников

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына кушымта
22.02.2019 №462

**ИСЕМЛЕК**
**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга махсус вәкаләтле затлар**

| ТРга тапшырылган дәүләт вәкаләтләре (өлкәләр буенча) | Дәүләт вәкаләтләрен тапшыру турында ТР законнары | Вәкаләтле муниципаль органнар, учреждениеләр (субвенцияләр алучылар) | Вәкаләтле вазыйфаи затлар, контрольлек итүче вазыйфаи затлар |
|---|---|---|---|
| Җирлекләргә финанс ярдәменең региональ фондыннан җирлекләргә дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча дәүләт вәкаләтләре | 2005 елның 22 декабрендәге 132-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты, «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе | Зеленодольск муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы муниципаль учреждениесе җитәкчесе» |
| Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләре | 2005 елның 30 декабрендәге 143-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты. | Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - мәгариф идарәсе башлыгы, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе рәисе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләре | 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты. | Зеленодольска муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (административ мәсьәләләр, террорчылыкка һәм экстремизмга каршы көрәш мәсьәләләре) (килешү буенча), Зеленодольск муниципаль районы административ комиссия рәисе |
| Гражданлык хәлләре актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләре | 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты, «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе (субвенцияләрне исәпләү өлешендә), Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр, опека һәм попечительлек), Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге башлыгы, «Зеленодольск муниципаль районының Финанс – бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе, Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | җирлекләренең башкарма комитет җитәкчеләре |
| Мәгариф өлкәсендә дәүләт вәкаләтләре | 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - мәгариф идарәсе җитәкчесе (килешү буенча); |
| Дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт вәкаләтләре | 2006 елның 7 апрелендәге 29-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр, опека һәм попечительлек), Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе җитәкчесе |
| Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләре | 2006 елның 11 декабрендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе (субвенцияләрне исәпләү өлешендә), Зеленодольск | «Зеленодольск муниципаль районының Финанс – бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе, Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары | |
| Күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләре | 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, «Зеленодольск муниципаль районы төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» Муниципаль бюджет учреждениесе | «Зеленодольск муниципаль районының төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» Муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе |
| Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт вәкаләтләре: йогышсызландыру, дезинсекция һәм дератизация үткәрү чараларын, тикшеренү лаборатор методларын кулланып үткәреләторган санитар-эпидемиягә каршы (профилактик) чараларны, йогышлы авырулар учакларында, шулай ук йогышлы авырулар барлыкка килү яисә таралу өчен шартлар булган территорияләрдә һәм | 2006 елның 16 мартындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр,опека һәм попечительлек) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| биналарда гамәлгә ашыруны оештыру | | | |
| Архив эше өлкәсендә дәүләт вәкаләтләре | 2007 елның 24 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты эшләр идарәчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге башлыгы |
| Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт вәкаләтләре | 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр, опека һәм попечительлек), Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе |
| Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча дәүләт вәкаләтләре | 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты. | Зеленодольска муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (административ мәсьәләләр, терроргчылыкка һәм экстремизмга каршы көрәш мәсьәләләре) (килешү буенча); |
| Хайваннар авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайваннар | ТР Законы № 9-ТРЗ, 20.05.2013 № 39-ТРЗ | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, | «Зеленодольск муниципаль районының төзелеш һәм инфраструктура үсеше |

| | | | |
|---|---|---|---|
| өчен уртак чирләрдән саклау чараларын уздыруны оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләре:<br>1) себер язвасы үләт базларын һәм биотермик чокырларны тоту, шул исәптән аларны төзекләндерү, гамәлдәге законнар нигезендә тиешле санитар халәткә китерү;<br>2) объектларның иминлеген тәэмин итү буенча чаралар күрү;<br>3) биотермик чокырларны консервацияләү<br>4) күзәтүчесез хайваннарны тоту;<br>5) вакытлыча тоту пунктында күзәтүчесез хайваннарны тоту;<br>6) күзәтүчесез хайваннар санын җайга салу (күзәтүчесез хайваннарны стерильләштерү (кастрацияләү), кеше һәм хайваннар өчен уртак авырулар ачыкланган, артык газаплар китереп чыгаручы, артык агрессив сукбай хайваннарны һәм күзәтүчесез хайваннарны бетерү). | | «Зеленодольск муниципаль районы төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» Муниципаль бюджет учреждениесе | департаменты» Муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча дәүләт вәкаләтләре бирелә. | Татарстан Республикасы законы №92-ТРЗ, 03.11.2015 | Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты, Зеленодольск муниципаль район Советы (килешү буенча) | Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге баш белгече (килешү буенча) |
| Җирдән файдалану һәм җирлек төзү кагыйдәләре расланган муниципаль район составына керүче шәһәр, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан, төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләре бирү вәкаләтләреннән тыш, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча дәүләт вәкаләтләре | 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, «Зеленодольск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» Муниципаль учреждениесе | «Зеленодольск муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе |
| Җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган һәм мөстәкыйль йөри яки әйләнә-тирә мохиттә ориентлаша алмаган, медицина ярдәме | Татарстан Республикасы Законы №50-ТРЗ, 10.07.2017 | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, «Айныткыч» МКСУ | Зеленодольска муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (административ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| күрсәтүгә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү буенча дәүләт вәкаләтләре | | | мәсьәләләр, террорчылыкка һәм экстремизмга каршы көрәш мәсьәләләре), «Айныткыч»МКСУ җитәкчесе; |